ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.06.2024 Мөслим авылы № 337

**«Спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентны раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 02 июлендәге 280 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы прокуратурасының 2024 елның 31 маендагы 02-08-01-2024 номерлы протестын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентны раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 02 июлендәге 280 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4 пунктындагы 2.4.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2.4.1. Спорт разрядын бирү өчен документларны карау срогы аларны теркәгән көннән башлап 16 эш көне тәшкил итә.

Спорт разрядын бирү яисә бирүдән баш тарту турында карар кабул итү спорт разряды бирү өчен документлар карау тәмамланган көннән алып 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

1.2. 2.5 пунктка түбәндәге абзацны өстәргә:

«з) Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2022 елның 19 декабрендәге 1255 номерлы боерыгы белән расланган Бердәм бөтенроссия спорт квалификациясе турында нигезләмәнең (МС спорт исемен бирү өчен) 50-53,55,69,71 пунктлары нигезендә спорт разряды бирү турында документ күчермәсе яисә өземтә;

и) спортның тиешле төре буенча спорт җыелма командасына кандидатлар исемлеген раслау турындагы боерык күчермәсе яисә боерыктан өземтә (Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләре чемпионатларыннан тыш);

к) спорт судьясы категориясе, халыкара спорт федерациясенә тиешле спорт төре буенча бирелгән документларның күчермәләре һәм таныкланган

күчермәләре һәм «Бөтенроссия категориясендәге спорт судьясы» таныклыкларының күчермәләре.

Документларның күчермәләре ярышлар судьяларын гамәлгә ашыручы судьялар коллегиясе составына кертелгән, спортчы нормаларны, таләпләрне һәм шартларны кимендә үтәгән спорт судьяларына тапшырыла: тиешле халыкара спорт федерациясенең календарь планына кертелмәгән халыкара ярышлар өчен - 6, калган ярышлар өчен 3.»;

л) региональ спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясе гамәлдә булуын туктатып тору турында башкарма хакимият органы документы күчермәсе (региональ спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясе гамәлдә булуын туктаткан очракта).».

1.3. Карарның 5 нче кушымтасын үзгәртергә һәм 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.В. Мөхсинов

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024елның 28 июнендәге
337 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазифаи затларның реквизитлары**

**Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 8 (85556) 2-54-90 | Irek.Salihzyanov@tatar.ru |
| Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары | 8 (85556) 2-46-07 | Ramil.Muhsinov@tatar.ru |
| Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы | 8 (85556) 2-59-48 | Ilshat.Yabbarov@tatar.ru |
| Бүлек белгече: | - | - |

**Мөслим муниципаль районы Советы**

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Район Башлыгы | 8 (85556) 2-45-00 | Albert.Huzin@tatar.ru |